**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА АХМЕТОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӘХМӘТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Әхмәт ав. **КАРАР**

17 октябрь 2025 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге Аксумла авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законның 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2025 елның 10 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка Аксумла авылы, Үзәк урамы, 51нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегендәге Аксумла авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Нагорная урамында яшәүче гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2025 елның 10 ноябрендә 09 сәгать 30 минутка Аксумла авылы, Үзәк урамы, 51нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегендәге Аксумла авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Мәктәп, Заречная урамында яшәүче гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2025 елның 10 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Аксумла авылы, Үзәк урамы, 51нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегендәге Аксумла авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Новая, Үзәк урамнарында яшәүче гражданнар Җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 2025 елның 10 ноябрендә 10 сәгать 30 минутка Аксумла авылы, Ягодная урамы, 11нче йорт янында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегендәге Аксумла авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Ягодная урамында яшәүче гражданнар Җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

7. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге Аксумла авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылапрдан тыш һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- урамнарны яктырту җайланмасы.

«РИЗА» «КАРШЫ».

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Аксумла авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әхмәт авыл җирлеге башлыгы Г.Н. Лизратова